ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

03 08 2020 г. № 502

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 12 ноябрендәге 2201 номерлы «Түбән Кама муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның 46 һәм 108 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 8 июнендәге 165-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 12 ноябрендәге 2201 номерлы «Түбән Кама муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» карарына (алга таба – карар) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

8.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8.3. Педагогик эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукына урта һөнәри яки югары белемгә ия булган һәм квалификация белешмәләрендә күрсәтелгән квалификация таләпләренә һәм (яки) һөнәри стандартларга җавап бирә торган затлар ия, әгәр башкасы «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнмәгән булса;

түбәндәге эчтәлекле 8.3.1. пунктын өстәргә:

«8.3.1. «Мәгариф һәм педагогик фәннәр» белгечлекләре һәм әзерлек юнәлешләре буенча югары белем бирү программалары буенча белем алучы һәм кимендә өч ел укыганга арадаш аттестацияне уңышлы узучы затларга төп гомуми белем бирү программалары буенча педагогик эшчәнлек белән шөгыльләнергә рөхсәт ителә.

Өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча педагогик эшчәнлек белән өстәмә белем бирү программалары юнәлешенә туры килә торган белгечлек һәм әзерлек юнәлеше буенча югары белем бирү программалары буенча белем алучы һәм кимендә ике ел укыганга арадаш аттестацияне уңышлы узучы затларга шөгыльләнергә рөхсәт ителә. Югары белем бирү программасының өстәмә гомуми белем бирү программасы юнәлешенә туры килүе эш бирүче тарафыннан билгеләнә.».

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы А.Р. Рамазановага йөкләргә

Җитәкче А.Г. Сәйфетдинов